РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

2022 елның 24 августы Кукмара ш. № 136

Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кукмара шәһәре җирлеге Советы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 өлешенең 5 пунктында «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 8 статьяның 22 пунктында «ясалма җир участогы булдыру турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 47 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктының тугызынчы абзацында «ясалма җир участогы булдыру турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 47 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктының икенче абзацында «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев